**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.05.2020 № 529

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары (2018 елның 3 маендагы 372 номерлы, 2018 елның 27 ноябрендәге 1003 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешенең 16 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында» 2009 елның 18 июлендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары (2018 елның 3 маендагы 372 номерлы, 2018 елның 27 ноябрендәге 1003 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым

категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче кушымтадагы җиденче абзацны төшереп калдырырга;

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча өстәргә:

«8) «Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында булган инвалидлык турында белешмәләр.».

2. Әлеге карар 2020 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин